# КАРАР

**2022 елның 16 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлегенең Сәрдәүч авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сәрдәүч авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Сәрдәүч авылында сүүткәргечне ремонтлау, кул белән һәм экскаватор белән грунтны эшкәртү, үткәргеч торба салу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

2022 елның 16 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 31 кеше.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 27 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 15.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 15 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Ошторма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Сәрдәүч авылының юлларына вак таш җәю, ремонтлау, төзекләндерү (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәрдәүч авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Сәрдәүч авылында суүткәргечне ремонтлау, кул белән һәм экскаватор белән грунтны эшкәртү, үткәргеч торба салу (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ошторма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев